**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2 Алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

1) Торак пункты территориясен яхшырту (Югары Сәрдә авылы территориясен чистарту (агачларны һәм куакларны кисү, үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү)).

2) Урамдагы ачык яктырту челтәрләрен, трансформаторны һәм алар өчен бүтән подстанцияләрне, участокларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны тәэмин итү өчен (урам яктырту техникасы (лампалар сатып алу)) ремонтлау.

3) Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Югары Сәрдә авылындагы зират территориясен чистарту (агачларны һәм куакларны кисү, үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү)).

4) Торак пункты чикләрендә җирле әһәмиятле җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (Югары Сәрдә авылында Алмяш, Тургай, Яшеллек урамнарындагы юл өслекләрен ремонтлау һәм урнаштыру (ватылган таш сатып алу, эш һәм хезмәт өчен түләү))."

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хөснетдинов Р.Р.

СОВЕТ ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1616006596